Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
Болын-Балыкчы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАРЫ

2020 ел, 29 гыйнвар № 1

Болын-Балыкчы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турындагы» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турындагы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакындагы» 196 номерлы карары нигезендә,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турындагы» карарына таянып Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. 2020 елның 1 февраленнән Болын-Балыкчы авыл җирлегендә,җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен әлеге карарның 1 нче һәм 2 нче кушымтасы нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, Апас муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Болын-Балыкчы авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Гыйлметдинова

1нче кушымта

Болын-Балыкчы авыл җирлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегендәге бәяләр

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Мәетне төрү | 1929,55 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 772,91 |
| 4. Мәетне (җәсәдләрен) зиратка илтү | 867 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2555,4 |
| Барлыгы | 6124,86 |

2нче кушымта

Болын-Балыкчы авыл җирлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегендәге бәяләр

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2389,56 |
| 3. Мәетне (җәсәдләрен) зиратка илтү | 919,2 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2816,1 |
| Барлыгы | 6124,86 |